# КАРАР

“17” ноябрь 2021 ел № 12

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Югары Пшалым авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 07 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Югары Пшалым авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 242,5 сум тэшкил иткэн, 1 нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 485 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча тубәндәге эшләргэ юнәлдеру белән килешәсезме:

1.Юл-урам челтәренә вак таштан юл полотносына нигез салу һәм каплау:
Тукай ур., 9 йорттан 1гә кадәр.

2.Юл-урам челтәренең вак грунтташ урнаштыру:
Тукай урамы 31дән 32 нче йортка кадәр;
Мичурин ур., 17 йорттан Сәлахова урамына кадәр;

3.Кече архитектура формасын сатып алу һәм балалар мәйданчыгын төзекләндерү;

4. Торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;

5. МТЗ-82 тракторы өчен асылмалы җиһазлар сатып алуны өлешчә финанслау (Ротор чапкычы, фронталь төягеч)

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен жибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 242 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 124 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 124 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Югары Пшалым авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Югары Пшалым авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 242,5 сум тэшкил иткэн, 1 нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 485 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдеру белән килешәсезме:

1.Юл-урам челтәренә вак таштан юл полотносына нигез салу һәм каплау:
Тукай ур., 9 йорттан 1гә кадәр.

2.Юл-урам челтәренең вак грунтташ урнаштыру:
Тукай урамы 31дән 32 нче йортка кадәр;
Мичурин ур., 17 йорттан Сәлахова урамына кадәр;

3.Кече архитектура формасын сатып алу һәм балалар мәйданчыгын төзекләндерү;

4. Торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;

5. МТЗ-82 тракторы өчен асылмалы җиһазлар сатып алуны өлешчә финанслау (Ротор чапкычы, фронталь төягеч)

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм халык күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендына югарыдагы адрес буенча урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Югары Пошалым авылы, Сәләхова урамы, 23 йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы М.П. В.Р.Габделхаков